**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.05.2026 № 09-39-6

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 06 июлендәге 09-16-88 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы Указы нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 06 июлендәге 09-16-88 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 23 мартындагы 09-16-42 номерлы, 2018 елның 04 октябрендәге 09-05-161 номерлы, 2022 елның 30 сентябрендәге 04-05-182 номерлы, 2023 елның 05 апрелендәге 04-05-44 номерлы, 2023 елның 18 сентябрендәге 09-07-10 номерлы, 2024 елның 27 маендагы 09-07-11 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Комиссия Дәүләт комитетының норматив хокукый акты нигезендә төзелә. Күрсәтелгән акт белән Комиссиянең составы һәм аның эш тәртибе раслана,

Комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

8 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) рәис урынбасары (Комиссия рәисе), Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасын башкаручы урынына калган зат (комиссия рәисе урынбасары), ришвәтчелек һәм башка хокук бозулар профилактикасы буенча дәүләт органының кадрлар хезмәте бүлекчәсе җитәкчесе яки ришвәтчелек һәм башка хокук бозулар профилактикасы буенча эш башкару өчен җаваплы дәүләт органының кадрлар хезмәте вазифаи заты (комиссия сәркатибе), Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан билгеләнә торган дәүләт хезмәте һәм кадрлар буенча бүлекчәдән, юридик (хокукый) бүлекчәдән, Дәүләт комитетының башка бүлекчәләреннән дәүләт хезмәткәрләре;»;

10 пункт:

«Килештерү сорау алынганнан соң 10 көн эчендә эшләнә.» сүзләрен төшереп калдырырга;

16 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын һәм дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибе таләпләрен үтәүен тикшерү нәтиҗәләре буенча (шул исәптән ришвәтчелеккә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасын кулланып уздырылган) түбәндәгеләрне раслаучы тикшерү материалларының тәкъдим ителүе:

дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән раслаган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәт вазифаларын биләүне дәгъваланучы гражданнар тарафыннан һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан табыш, милек һәм милки характерлы бурычлар турында мәгълүматларның тәкъдим ителүе турында Нигезләмәдә билгеләнгән шикле яки тулы булмаган мәгълүматларның тәкъдим ителүе турында;

дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәмәүе турында;»;

22 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән раслаган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәт вазифаларын биләүне дәгъваланучы гражданнар тарафыннан һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан табыш, милек һәм милки характерлы бурычлар турында мәгълүматларның тәкъдим ителүе турында Нигезләмә нигезендә тәкъдим ителгән мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын билгеләргә;».

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис М.Г.Зиатдинов